РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЗНАКАЕВО АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин ур.,14 нче йорт, Азнакай ш., 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.11.2024 ел. № 35

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә җирләү мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган оешманы билгеләү турында

1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы "Җирләү һәм күмү эше турында"гы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законнар, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Нигезләмәсе нигезендә, Азнакай шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча күптармаклы җитештерү предприятиесе+» акционерлык җәмгыятен (алга таба – «МППБиО+» АҖ) Азнакай шәһәре территориясендә җирләү мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган оешма итеп билгеләргә.
2. «Төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча күптармаклы җитештерү предприятиесе+» акционерлык җәмгыятен Азнакай шәһәре территориясендә җирләү эше буенча чаралар оештырырга тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.Ә. Габдрахманов